СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Мульма, ул. Центральная, д. 46А

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46А

тел./факс 8(84365) 70-2-03 e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**17 декабрь 2024 ел** **№116**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Уставы, Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гатауллин